Республика Татарстан
Менделеевский
муниципальный район
Глава города
Менделеевск

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы
Менделеевск Шәһәре
башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.12.2023 ел Менделеевск ш. №73

"Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре"
муниципаль берәмлегенең чикләрен үзгәртү
буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы халкының Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре муниципаль берәмлеге чиген гавами тыңлаулар уздыру юлы белән үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында,

Карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2023 елның 18 декабрендәге 229 номерлы карарында белдерелгән «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә керә торган җир кишәрлекләрен «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә кертүне карау турында гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарны 2023 елның 19 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырырга.

3. Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йортта урнашкан администрация бинасының актлар залын 2024 елның 29 гыйнваре 17 сәгать 00 минутта гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәр советының 2018 елның 7 августындагы 60 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами

тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга, гавами тыңлауларда катнашу өчен түбәндәге адрес буенча Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт, 1 кат, район Советының оештыру комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр) шәхсән яисә почта буенча (конвертта «муниципаль берәмлекнең чикләрен үзгәртү турында фикер алышу» дигән тамга белән) гаризалар бирелергә мөмкин.

5. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы 2024 елның 29 гыйнварына кадәр

6.Советның оештыру комитетына Менделеевск муниципаль районы Советының 2023елның 18 декабрендәге 229 номерлы карарында күрсәтелгән инициативаны карау буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район башлыгы Р.И.Беляев

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

Район башлыгы урынбасары Л.К. Галиева

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева